**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

09.01.2024 № 3

**Татарстан Республикасы Президентының «Аерым категориядәге затларның үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле рәвештә бүләк алулары турында хәбәр итүе, бүләкне тапшыру һәм аның бәясен билгеләү, сату (түләп алу) һәм аны сатудан алынган акчаны хисапка кертү тәртибе турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Аерым категориядәге затларның үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле рәвештә бүләк алулары турында хәбәр итүе, бүләкне тапшыру һәм аның бәясен билгеләү, сату (түләп алу) һәм аны сатудан алынган акчаны хисапка кертү тәртибе турында» 2014 елның 27 гыйнварындагы 94 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 24 июнендәге 389 номерлы һәм 2022 елның 21 сентябрендәге 303 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә» сүзләренә алмаштырырга;

2 һәм 3 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле рәвештә бүләк алулары турында хәбәр итүе, бүләкне тапшыру һәм аның бәясен билгеләү, сату (түләп алу) һәм аны сатудан алынган акчаны хисапка кертү тәртибе турында нигезләмәне кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2024 елның «09» гыйнварындагы
3 номерлы боерыгына
кушымта

**Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алулары турында хәбәр итүе, бүләкне тапшыру һәм аның бәясен билгеләү, сату (түләп алу) һәм аны сатудан алынган акчаны хисапка кертү тәртибе турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алулары турында хәбәр итүе, бүләкне тапшыру һәм аның бәясен билгеләү, сату (түләп алу) һәм аны сатудан алынган акчаны хисапка кертү тәртибе билгеләнә.

Әлеге Нигезләмәнең гамәле Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе тарафыннан бүләк алуга бәйле барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

2. Әлеге Нигезләмәдә күздә тотылган максатлар өчен түбәндәге төшенчәләр файдаланыла:

протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә алынган бүләк – бүләк бирелә торган затның вазыйфа биләвеннән яисә аның вазыйфа башкаруыннан чыгып бүләк тапшыра торган физик (юридик) затлардан, протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар вакытында әлеге чараларда катнашучы һәркемгә аларга хезмәт вазыйфаларын башкару максатларында тапшырылган канцелярия кирәк-яракларыннан, чәчәкләрдән һәм бүләкләү буларак тапшырылган кыйммәтле әйберләрдән тыш, дәүләт вазыйфасы биләүче зат, хезмәткәр тарафыннан алынган бүләк;

протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм хезмәт вазыйфалары башкаруы сәбәпле катнашкан башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алу – дәүләт вазыйфасы биләүче зат, хезмәткәр

тарафыннан шәхсән яисә арадашчы аша физик (юридик) затлардан вазыйфаи регламентында каралган эшчәнлекне башкарганда, шулай ук әлеге затларның һөнәри һәм хезмәт эшчәнлегенең хокукый нигезләмәләрен һәм үзенчәлекләрен билгеләүче федераль законнарда һәм башка норматив актларда каралган очракларда хезмәт вазыйфаларын башкаруы белән бәйле бүләк алу.

3. Дәүләт вазыйфасын биләүче затларның, хезмәткәрләрнең физик (юридик) затлардан, аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә алынган бүләкләрдән тыш, үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле рәвештә бүләк алырга хакы юк.

4. Дәүләт вазыйфасы биләүче зат, хезмәткәр аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә барлык бүләк алу очраклары турында әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенә хәбәр итәргә тиеш.

5. Кушымта нигезендә форма буенча төзелгән, аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алу турындагы хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) бүләк алынган көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсенә (алга таба – вәкаләтле структур бүлекчә) бирелә. Хәбәрнамәгә бүләкнең бәясен раслаучы документлар (касса чегы, товар чегы, бүләк өчен акча түләнгәнне белдергән башка документ) (булган очракта) теркәлә.

Бүләк хезмәт командировкасы вакытында алынган очракта, хәбәрнамә бүләк алган зат хезмәт командировкасыннан кайтканнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш.

Әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацларында күрсәтелгән срокларда дәүләт вазыйфасы биләүче зат, хезмәткәргә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында хәбәрнамә бирү мөмкин булмаган очракта, хәбәрнамә әлеге сәбәпләр бетерелгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

6. Хәбәрнамә ике нөсхәдә төзелә, аларның берсе теркәү турында билге куеп, хәбәрнамә биргән затка кире кайтарыла, ә икенче нөсхәсе бухгалтерлык хисабына алу турындагы законнар нигезендә төзелгән Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе активлары керү һәм чыгу буенча комиссиягә (алга таба – комиссия) җибәрелә.

7. Бәясе документлар нигезендә расланган һәм 3 меңнән артып киткән яисә аны алган хезмәткәргә аның бәясе билгеле булмаган бүләк тиешле теркәү журналында хәбәр теркәлгән көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча вәкаләтле структур бүлекчәнең бүләкне кабул итү-тапшыру акты буенча саклауга алган җаваплы затына тапшырыла.

8. Дәүләт вазыйфасын биләүче зат тарафыннан алынган бүләк, аның бәясенә бәйсез рәвештә, әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында карлаган тәртиптә саклауга тапшырылырга тиеш.

9. Бүләк кабул итү-тапшыру акты буенча тапшырылганчы, бүләкне югалткан өчен яисә аның зарар күрүе өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә бүләкне алган зат җаваплы була.

10. Бүләкне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бухгалтерлык исәбенә алу, аның бәясен билгеләү бүләкне исәпкә алу датасына гамәлдә булган базар бәясе яисә охшаш шартларда шундый ук кыйммәтле матди әйбер бәясе нигезендә, кирәк булган очракта комиссияне эшкә җәлеп итеп башкарыла.

Базар бәясе турындагы белешмәләр документлар нигезендә, ә документлар нигезендә билгеләү мөмкин булмаганда, экспертлар җәлеп итү юлы белән билгеләнә. Бүләк, аның бәясе өч мең сумнан артып китмәгән очракта, аны тапшырган затка кабул итү-тапшыру акты буенча тапшырыла.

11. Вәкаләтле структур бүлекчә билгеләнгән тәртиптә бухгалтерлык исәбенә алынган, бәясе өч меңнән арткан бүләкне Татарстан Республикасының Дәүләт милке реестрына кертүне тәэмин итә.

12. Бүләкне тапшырган дәүләт вазыйфасын биләүче затның, хезмәткәрнең аны тапшырган көннән ике айдан да соңга калмыйча эшкә алучы вәкиленә (Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә) тиешле гариза юллап, бүләкне сатып алу мөмкинлеге бар.

13. Вәкаләтле структур бүлекчә, әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән гариза алынган көннән өч ай дәвамында бүләкне сату (сатып алу) өчен аның бәясен билгеләүне оештыра һәм гариза биргән затка бәяләү йомгаклары турында язма рәвештә хәбәр җибәрә, шуннан соң гариза бирүче бер ай эчендә бәяләү нәтиҗәсендә билгеләнгән бәягә бүләкне сатып ала яисә сатып алудан баш тарта.

14. Кыйммәтле металлардан һәм (яисә) асылташлардан эшләнгән бүләккә карата дәүләт вазыйфасын биләүче заттан, хезмәткәрдән әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән гариза алынмаган очракта яисә әлеге затлар мондый бүләкне сатып алудан баш тартса, кыйммәтле металлардан һәм (яисә) асылташлардан эшләнгән бүләк вәкаләтле структур бүлекчә тарафыннан «Россия Федерациясе Финанс министрлыгы каршындагы Россия Федерациясе кыйммәтле металлар һәм асылташлар дәүләт фондын формалаштыру, кыйммәтле металларны һәм асылташларны саклау, тапшыру һәм файдалану буенча дәүләт учреждениесе (Россия Гохран)» федераль казна учреждениесенә Россия Федерациясе кыйммәтле металлар һәм асылташлар дәүләт фондына кертү өчен тапшырыла.

15. Аңа карата әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән гариза алынмаган бүләк, комиссиянең бүләкне Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе эшчәнлеген тәэмин итү өчен файдалануның максатка ярашлылыгы турында нәтиҗәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе тарафыннан файдаланыла ала.

16. Бүләкне файдалану максатка яраксыз булган очракта, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан бүләкне сату

һәм бүләкне сату (сатып алу) өчен вәкаләтле структур бүлекчә тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә сәүдә уздыру аша оештырыла торган аның бәясен билгеләүне башкару турында карар кабул ителә.

17. Әлеге нигезләмәнең 13 һәм 16 пунктларында каралганча бүләкне сату (сатып алу) өчен аның бәясен билгеләү Россия Федерациясенең бәяләү эшчәнлеге турында законнары нигезендә бәяләү эшчәнлеген башкаручы субъектлар тарафыннан башкарыла.

18. Бүләк сатып алынмаган яисә сатылмаган очракта, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан бүләкне кабаттан сату яисә аны хәйрия оешмасы балансына түләүсез тапшыру яисә Россия Федерациясе Законнары нигезендә аны юкка чыгару турында карар кабул ителә.

19. Бүләкне сатудан (сатып алудан) алынган акча Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемнә күчерелә.

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алулары турында хәбәр итүе, бүләкне тапшыру һәм аның бәясен билгеләү, сату (түләп алу) һәм аны сатудан алынган акчаны хисапка кертү тәртибе турында нигезләмәгә
кушымта

Форма

**Бүләк алу турында хәбәрнамә**

Татарстан Республикасы Рәисе
(дәүләт органының вәкаләтле

Эшләр идарәсенә
структур бүлекчәсе атамасы)

___

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта),

били торган вазыйфасы)

Бүләк алу турында 20___ елның «____» _____________ хәбәрнамә.

___
(протокол чарасы, хезмәт командировкасы, башка рәсми чара атамасы,

уздыру урыны һәм датасы)

(бүләкне алу датасы)

бүләк(ләр) алу турында хәбәр итәм.

| Бүләкнең атамасы | Бүләкнең характеристикасы, тасвирламасы | Предметларның саны | Сумнарда бәясе* |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| 3. | | | |

Барлыгы

Кушымта: ____________________________________ __________биттә.
(документның атамасы)

Хәбәрнамә биргән
зат ____________ ______________ 20__ елның «___»______
(имзасы) (имзаны шәрехләү)

Хәбәрнамәне кабул
итеп алган зат ____________ ______________ 20__ елның «__»_______
(имзасы) (имзаны шәрехләү)

Хәбәрнамәләрне теркәү журналында теркәү номеры ________________
20___ елның «___»________________

Искәрмә:
* Бүләкнең бәясен раслый торган документлар булганда тутырыла.